| МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

| ПРИКАЗ | Казан шәһәре | БОЕРЫК |
|---|---|---|
| 29.11.2017 | | 1428-п |

**Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Яңа Мичән торак пунктында эчә торган су чыганагының (чишмәнең) санитар саклык зоналары проектын раслау турында**

Россия Федерациясе Су кодексы, «Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында» 1999 елның 30 мартындагы 52-ФЗ номерлы Федераль закон, «Су белән тәэмин итү чыганакларының һәм эчә торган су үткәргечләренең санитар саклык зоналары. СанПиН 2.1.4.1110-02» санитария кагыйдәләре һәм нормалары, «Җир асты суларын пычранудан саклауга карата гигиена таләпләре. СП 2.1.5.1059-01» санитария кагыйдәләре, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы мәсьәләләре» 2005 елның 6 июлендәге 325 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә эчә торган су һәм хуҗалык-көнкүрештә су белән тәэмин итү өчен кулланыла торган су объектларының санитар саклык зоналары проектларын раслау тәртибе турында» 2012 елның 29 февралендәге 177 номерлы карары нигезендә һәм 2017 елның 17 ноябрендәге судан файдалану турында №16-11.01.00.003-Р-ДЗИО-С-2017-02465/00 килешүне, Кулланучылар хокукларын яклау һәм кешенең уңай тормышы өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсенең Саба, Мамадыш, Кукмара районнарындагы территориаль бүлегенең (Саба ТБ) проектның дәүләт санитар-эпидемиология кагыйдәләренә һәм нормативларына туры килүе турында 2016 елның 24 ноябрендәге № 16.18.27.000.Т.000014.11.16 бәяләмәсен исәпкә алып, шулай ук «Саба районы торак-коммуналь хуҗалыгының Шәмәрдән күптармаклы җитештерү предприятиесе» ААҖ тәкъдим иткән Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Яңа Мичән торак пунктында эчә торган су белән тәэмин итү чыганагының (чишмәнең) санитар саклык зоналарын оештыру проекты нигезендә

боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Яңа Мичән торак пынктында эчә торган су чыганагының (чишмәнең) санитар саклык зонасы проектын (алга таба – Проект) расларга.

2. 1 нче кушымта нигезендә су алу җайланмасының санитар саклык зоналары чикләрен билгеләргә.

3. 2 нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Яңа Мичән торак пунктында су белән тәэмин итү чыганагының

(чишмәнең) санитар саклык зонасы чикләрендә территорияләрдән хуҗалык өчен файдалану режимын билгеләргә.

4. Проект күчермәсен Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетына җибәрергә.

5. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә түбәндәге чараларны үткәрергә тәкъдим итәргә:

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Яңа Мичән торак пунктында эчә торган су белән тәэмин итү чыганагының (чишмәнең) санитар саклык зонасының чикләре, су алу җайланмасының санитар саклык зонасы чикләрендәге территорияләрдән хуҗалыкта файдалану кагыйдәләре һәм режимы турында халыкка хәбәр итүне оештыру турында;

территорияләр үсешенең территориаль комплекс схемаларын, функциональ зоналарга бүлү схемаларын, җир корылышы схемаларын, районнарны планлаштыру проектларын һәм генераль планнарны эшләгәндә Проектны исәпкә алуны оештыру турында.

Министр Ф.С. Габделганиев

Татарстан Республикасы
Экология һәм табигать
ресурслары министрлыгының
29.11.2017 № 1428-п
боерыгына 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Яңа Мичән торак пунктында эчә торган су чыганагының (чишмәнең) санитар саклык зоналары чикләре**

Яңа Мичән торак пунктында хуҗалык-эчәр су белән тәэмин итү өчен файдаланыла торган «Саба районы ТКХ Шәмәрдән күптармаклы җитештерү предприятиесе» ААҖ чишмәдән су алу корылмасы Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Яңа Мичән торак пунктының көньяк-көнчыгыш читендә, Кече Мишә елгасы үзәненең сул як яр буеның аскы өлешендә урнашкан.

Судан файдалану урынының географик координатлары: төньяк киңлектә: $56^0 02'15,42''$ , көнчыгыш озынлыкта: $50^0 16'48,8''$.

Санитар саклык зоналары өч пояс составына оештырыла: беренче пояс (катгый режимлы) су алу корылмасы урнашкан территорияне, барлык суүткәргеч корылмаларының һәм су үткәрү каналы мәйданчыкларын үз эченә ала. Икенче һәм өченче пояслар (чикләүләр пояслары) су белән тәэмин итү чыганагы пычрануын кисәтү өчен билгеләнгән территорияне үз эченә ала.

Санитар саклык зонасының I поясы

Чишмә янында пычрату чыганакларының булмавы, шулай ук техник мөмкинлекне исәпкә алып, беренче пояс түбәндәгечә билгеләнә: көнчыгыш юнәлештә (агым буенча өскә таба) – 40 метр, төньякта – 30 метр, көнбатыш юнәлештә (агым буенча аска таба) – 10 метр, көньякта – 30 метр, төньяк-көнчыгыш һәм көньяк-көнчыгышта – 50 метр.

Санитар саклык зонасының II поясы

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Яңа Мичән торак пунктында чишмәдән су алу җайланмасының санитар саклык зонасындагы икенче поясының гомуми озынлыгы – $L$=290 метр (җир асты сулары агымы буенча аска таба $r$ = 50 метр, җир асты сулары агымы буенча өскә таба $R$ = 240 метр). Үзәк өлештә санитар саклык зонасының $d$ II поясының киңлеге – 180 метр.

Санитар саклык зонасының III поясы

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Яңа Мичән торак пунктында чишмәдән су алу җайланмасының санитар саклык зонасындагы өченче поясының гомуми озынлыгы – $L$=2550 метр (җир асты сулары агымы буенча аска таба $r$ = 50 метр, җир асты сулары агымы буенча өскә таба $R$ = 2500 метр).

Үзәк өлештә санитар саклык зонасының $d$ III поясының киңлеге – 800 метр.

Татарстан Республикасы
Экология һәм табигать
ресурслары министрлыгының
29.11.2017 № 1428-п
боерыгына 2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Яңа Мичән торак пунктында эчә торган су чыганагының (чишмәнең) санитар саклык зонасы чикләрендә территорияләрдән хуҗалык өчен файдалану режимы**

1. Санитар саклык зоналарының беренче поясы

1.1. Санитар саклык зонасындагы беренче пояс территориясе өслек агымын аннан читкә агызып җибәрү өчен планлаштырылган, яшелләндерелгән, коймалап алынган һәм сак белән тәэмин ителгән булырга тиеш. Корылмаларга бара торган юллар каты өслекле булырга тиеш.

1.2. Санитар саклык зонасындагы беренче пояс территориясендә түбәндәгеләр рөхсәт ителми: биек кәүсәле агачлар утырту, төзелешнең су үктәрү корылмаларын эксплуатацияләү, үзгәртеп кору һәм киңәйтүгә турыдан-туры кагылышы булмаган барлык төрләре, шул исәптән төрле билгеләнештәге торбаүткәргечләр салу, торак һәм хуҗалык-көнкүреш биналары урнаштыру, кешеләрне яшәтү, агулы химикатлар һәм ашламалар куллану.

1.3. Санитар саклык зонасының беренче поясы территориясендәге биналар ташландык суларны көнкүреш яки эшчәнлек канализациясенең иң якын системасына яки санитар саклык зонасындагы беренче поястан читтә икенче пояс территориясендәге санитар режимны исәпкә алып урнаштырылган җирле чистарту корылмалары станцияләренә агыза торган канализация белән җиһазландырылырга тиеш.

Искәрмәле очракларда, канализация булмаса, санитар саклык зонасының беренче поясы территориясе пычрануга юл куймый торган, нәҗесләрне һәм көнкүреш калдыкларын кабул итү өчен су үткәрми торган корылмалар төзелергә тиеш.

1.4. Санитар саклык зонасының беренче поясында урнашкан су үткәрү корылмалары скважина очлыклары һәм скважина авызлары, резервуарларның люклары һәм агызу торбалары һәм насосларга су тутыру җайланмалары пычрану мөмкинлеген калдырмауны исәпкә алып җиһазландырылырга тиеш.

1.5. Су алу корылмаларының барысы да су алу корылмасын проектлаганда һәм санитар саклык зонасы чикләрен нигезләгәндә каралган проект җитештерүчәнлегендәге су алу корылмасын эксплуатацияләгәндә фактик дебитның туры килүенә системалы тикшерү уздыру аппаратурасы белән җиһазландырылырга тиеш.

## 2. Икенче һәм өченче пояслар буенча чаралар

2.1. Сулы горизонтларны пычрату ихтималлыгы өлешендә куркыныч тудыра торган барлык искергән, эшләми торган, җитешсезлекләре булган яки дөрес эксплуатацияләнми торган скважиналарны ачыклау, цементлау яки торгызу.

2.2. Яңа скважиналарны бораулау һәм яңа төзелешнең туфрак катламын бозуга бәйле эшләре дәүләт санитар-эпидемиология күзәтчелеге үзәге белән мәҗбүри килештереп гамәлгә ашырыла.

2.3. Яраксызланган суларны җир асты су горизонтларына агызуны, каты калдыкларны җир астында урнаштыруны һәм җир асты байлыклары белән эшләр башкаруны тыю.

2.4. Ягулык-майлау материаллары, агулы химикатлар һәм минерал ашламалар складлары, сәнәгый агынтыларны туплау, шлам саклау җайланмаларын һәм җир асты суларын химик пычрату куркынычы белән аңлатыла торган башка объектларны урнаштыруны тыю.

Мондый объектларны санитар саклык зоналарының өченче поясы чикләрендә урнаштыру бары тик якланган җир асты суларыннан файдаланганда гына, сулы горизонты саклау буенча махсус чаралар үтәү шарты белән, геологик контрольлек органнары бәяләмәсен исәпкә алып бирелгән дәүләт санитар-эпидемиология күзәтчелеге үзәгенең санитар-эпидемиология бәяләмәсе булган очракта гына рөхсәт ителә.

2.5. Файдаланыла торган сулы горизонтка турыдан-туры гидрологик бәйләнеше булган җир өсте суларын санитар саклаганда җир өсте суларын саклауга карата гигиена таләпләре нигезендә кирәкле чараларны үз вакытында башкару.